وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№22 (165). 30 ноябрь 2012 / 16-мөхәррәм-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



КАЗАНДА ВӘЛИУЛЛА ЯКУПОВ МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ ▷2◁



МӘУЛА КОЛЫЙ ХИКМӘТЛӘРЕНЕҢ КЫЙММӘТЕ ▷3◁




СӨЕКЛЕ РӘСҮЛЕБЕЗ (СГВ) ТӘКЪДИМ ИТКӘН ДӘВА ▷4◁

## Коръән укучылар бәйгесенә көтәбез!

**Тарихи-мәдәни мирас елы кысаларында игълан ителгән Коръән елы уңаеннан, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте республика күләмендә Коръән укучылар бәйгесен оештыра.**

**Һәрбер катнашучыдан аерым осталык, зур җаваплылык сорый торган әлеге бәйге пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (сгв) иңдерелгән Коръәни-Кәримнең илаһи аһәңен тоярга мөмкинлек бирәчәк.**

**Габдерраззак һәм башка мөхәддисләр риваять итә торган хәдистә Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте: «Һәр нәрсәнең үз бизәге бар, ә Коръәннең бизәге – матур тавыш». (Кешеләр) сорадылар: «Әгәр кешенең тавышы матур булмаса?» (Моңа) ул әйтте: «Булдыра алган кадәр матур укырга тырышсын» (Изгеләр бакчасы).**



**Риваять ителә: «Әбу Өмәмә (разыяллаһү ганһү) әйтте: “Мин Аллаһ Илчесе галәйһиссәләмнең: “Коръән укыгыз, чөнки, дөреслектә, Кыямәт көнендә ул укыганнар өчен шәфәгатьче булып киләчәк”, – дип әйткәнен ишеттем» (Мөслим).**

**Бәйгенең әһәмияте дә шунда: Коръәни-Кәримне уку һәм тыңлау күңелләребезгә рухи азык кына биреп калмый, ә гамәл дәфтәрләребезгә игелекле бер гамәл буларак та теркәлә.**

**Бәйге 1 декабрь көнне Россия ислам университетында узачак. Бүгенге көндә конкурста катнашырга Татарстанның төрле районнарында яшәүче кырыктан артык кеше теләк белдерде.**

**Коръән елы кысаларында мондый төрдәге бәйгеләр үткәрү матур бер традициягә әйләнде: апрель һәм март айларында мөхтәсибәтләрдә үткәрелсә, ноябрь-декабрь айларында республика һәм Россия күләмендә уздырыла. Әлеге бәйге – йомгаклау бәйгесе.**

**Ул республикабыз районнарында җиңеп чыккан кардәшләребезне бергә җыеп, аларга 3 номинация буенча сәләтләрен күрсәтергә мөмкинлек бирәчәк:**

**1. Коръәннең утызынчы җүзеннән яртысын белү;**
**2. Коръәннең утызынчы җүзен белү (“Гаммә” җүзе);**
**3. Коръәнне дөрес уку.**

**Бәйгедә катнашучылар Россия ислам университетындагы Коръән-хафизлар үзәгенең эшчәнлеге белән танышачаклар.**

**Җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр тапшырылачак.**

**Мондый төрдәге бәйгеләрне үткәрү традициясе киләчәктә дә дәвам итәчәк. Аллаһы Тәгалә сүзен киләсе буыннарга җиткерүдә һәрбарчабыз да өлешен кертер, дип чын күңелдән ышанып каласы килә.**

*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

## Мөселман кардәшләребез — Көнбатышта

**Гыйбадәтханәне ул төзелгән ташлар олыламый, киресенчә, гыйбадәтханә үзе ул ташларга мәгънә бирә.**
***(Антуан де Сент-Экзюпери)***

Мөселманнарның мөселман булмаган Көнбатыш җәмгыятьләрендә тамыр җәю проблемасы ислам динен тотучылар белән башка дин һәм яшәеш мәсләкләренең тарафдарлары арасындагы мөнәсәбәтләр даирәсендә XX йөз урталарыннан башлап әлегәчә иң актуаль һәм кискен мәсьәләләрнең берсе булып тора. Әледән әле бу илләрнең иҗтимагый тормышында җәнҗаллар чыгып, мөселманнарга каршы ниндидер чыгышлар яки киресенчә булган вакыйгалар уңае белән протест күрсәтү дулкыннары да булгалый. Андый конфронтацияләр еш кына шәхси-көнкүреш кысаларыннан чыгып та китәләр һәм кайвакыт Көнбатыш илләренең хакимият органнары тарафыннан да оештырылып җибәреләләр. Франциядә, мәсәлән, җәмәгать урыннарында никаб киеп йөрүне тыю турында 2010 елда кабул ителгән канунны гына да искә төшереп үтү җитәр. Шундый ук канун Бельгиядә дә кабул ителде.

Әлбәттә, мондый очракларда Ислам тарафдарларының дини хисләрен аңларга була, алар Көнбатыш илләре хакимият даирәләренең моның ише сәяси активлыкларын, мөселманнарны дини мотивлар буенча кысу һәм дискриминацияләү дип кабул итәләр. Бу очракта, Көнбатыш демократиясенең сыйфаты буенча куелган сораулар бик урынлы: ул демократия үзе игълан иткән принциплар буенча абсолют чикләрдә эш итәме, әллә кешеләрне категорияләренә карап сайлап алу юлы белән барамы?

"... Мөселманнарга карата бельгиялеләрнең башка стандартлар кулланылуы аңлашыла башлый. Безгә мөнәсәбәт башка, безнең өчен аерым кануннар языла, чөнки без җәмгыятьнең башка өлешләреннән, өстенлек итүче нормативлардан аерылып торабыз һәм аның эченә органик рәвештә кереп китә алмыйбыз" (Изабель Прэль - Бельгиянең мөселман башкарма оешмасы вице-президенты, http://nohchipress.info).

Ләкин бу проблеманың башка ягы да бар. Ул мөселманнарның үзләренә, аларның бу илләргә барып чыгу сәбәпләреннән башлап, аларның шактый өлешенең яңа мәдәни-этник шартлардагы яшәү рәвеше, тәртибе һәм дә социаль-сәяси ак-



тивлыгына кадәр кагыла.

Көнбатыш илләрендә мөселман иммигрантлар барлыкка килү тарихын карап карыйк. Бу феномен сәбәпләрен, метрополиягә элеккеге колонияләрдән чыгучыларның килеп төпләнүенә сылтау ясап, мөселман дөньясының элеккеге колониаль үткәненә генә калдырып калып булмый. Алай аңлату мөселман Шәрыгындагы сәясәтнең традицион уенчылары - Франция белән Бөекбритания өчен кабул итәрлек дип исәпләнә алырга мөмкин кебек булса да, Германия, АКШ, Канада һәм күп кенә башка илләр өчен кабул итәрлек түгел, чөнки бу илләрнең мөселман дөньясында колонияләре булмаган, ләкин, шуңа да карамастан, бу илләрдә мөселманнарның өлеше ярыйсы гына.

Мөселманнарның Көнбатыш дөньясына массакүләм килеп төпләнүләренең сәбәпләре нидә соң? Сәбәбе бик гади: кеше кайда яхшы, шуны эзли, мөселманнар да бу универсаль кагыйдәгә искәрмә

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### МӘРҖАНИ МӘЧЕТЕНДӘ КОРЪӘН ДӘРЕСЛӘРЕ УЗА

**Октябрь аеннан Казан шәһәренең Мәрҗани мәчетендә изге Коръән китабын дөрес һәм матур уку буенча махсус дәресләр үткәрелә башлады.**

Укулар сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә кичке сәгать биштән (17.00) җидегә кадәр (19.00) үтә. Дәресләрне Казан ислам колледжының иң яхшы укучы шәкертләре алып бара. Биредә Коръән дәресләреннән тыш, Ислам нигезләре дә өйрәтелә.

Әлеге курсларга теләгән бар кеше дә йөри ала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Арагызда иң яхшылары шулардыр ки, кем Коръәнне өйрәнә һәм башкаларга да өйрәтә", - дип әйткән.

### "САБЫЙГА" АКЦИЯСЕНӘ ЙОМГАК ЯСАЛДЫ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия бүлеге һәм "Болгар" радиосы тарафыннан оештырылган "Сабыйга" акциясенә йомгак ясалды.**

Акция дәвамында подгузниклар, бала чүпрәкләре, кечкенә бала киемнәре һәм гигиена кирәк-яраклары җыелды. Акциядә урта хәлле кешеләр, пенсионерлар һәм студентлар катнашты. Җыелган әйберләр Казан шәһәренең 2 нче балалар йортына тапшырылды.

Мондый төр акция өченче тапкыр үткәрелде. Исегезгә төшерәбез, беренче акция дәвамында җыелган әйберләр Казан шәһәренең йогышлы авырулар хастаханәсендәге, икенче акциядә җыелганнары - Бөгелмә хастаханәсендәге ташландык балаларга тапшырылган иде.

### СТУДЕНТЛАР КӨЧ СЫНАШТЫ

**28 ноябрь көнне РИУның актлар залында Студентлар дебаты турнирының (Хатын-кызлар лигасы) өченче этабы үтте.**

РИУның матбугат үзәге хәбәр иткәнчә, бәйгенең икенче турында катнашучылар "Пробиркадагы бала: әйе яисә юк?" соравына җавап табарга тырышты.

### БӨГЕЛМӘ ХАҖИЛАРЫ КОРБАН АШЫНА ҖЫЕЛА

**Бүген көндезге сәгать икедә (14.00) Бөгелмәнең Җәмигъ мәчетендә агымдагы елда һәм аннан алда хаҗ сәфәрендә булган мөселман кардәшләребез өчен Корбан ашы үтәчәк.** Узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап бүгенге көнгә кадәр вакытны алсак, Бөгелмәдә хаҗилар саны йөз иллеләп кешегә җиткән. Әлеге чарада мәхәллә халкы да катнашачак, хаҗилар изге сәфәрдән алып кайткан тәэсирләре белән дә уртаклашачак. Коръән укылып, хаҗиларга "Иң яшь хаҗи", "Иң өлкән яшьтәге хаҗи" кебек исемнәр тапшырылачак. Шулай ук мөселманнар изге зәм-зәм суы белән сыйланачак.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# Казанда Вәлиулла Якупов музее ачылды

**29 ноябрь көнне "Иман" ислам мәдәнияте мәркәзендә үзәк оешуга багышланган XXI корылтай булып узды. Вакыйга уңае белән "Касыймия" мәдрәсәсе бинасында Апанай мәчетенең элеккеге имамы, дин юлында күп хезмәтләр куйган, озак еллар мәркәзнең җитәкчесе булган шәхес - Вәлиулла хәзрәт Якупов музее ачылды.**



Корылтай эшендә Апанай мәчете имамы, "Иман" ислам мәдәнияте үзәге җитәкчесе Наил Гарипов, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, "Мөслимә" иҗтимагый оешмасы рәисе Әлмира Әдиятуллина, Вәлиулла Якуповның хезмәттәшләре, фикердәшләре, дин белгечләре катнашты.

Әйтергә кирәк, 20 елдан артык вакыт эчендә "Иман" үзәге тарафыннан меңнән артык басма хезмәт дөнья күргән. Оешма "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен, Апанай мәчетен торгызуда һәм мөселманнарга "Касыймия" мәдрәсәсен кайтаруда катнашкан. Үзәкнең хәзерге җитәкчесе Наил Гарипов Вәлиулла хәзрәт исән чакта ук "Иман" мәркәзенә фәнни эшчәнлек алып бару өчен чакырылган булган. "Ни кызганыч, агымдагы елның 19 июлендә безнең остазыбыз, җитәкчебез үтерелде, әмма безгә аның башлаган эшләрен дәвам иттерергә, хәзрәтнең идеяләрен тормышка ашыру юлында тырышырга кирәк", - дип, Наил Гарипов үз сүзен тетрәндергеч вакыйгаларны искә алудан башлады. Аның сүзләренә караганда, дини журналлар ай саен чыгып килә. "Бүгенге көндә безнең көн саен яңартыла һәм экстремистик эшчәнлеккә каршы көрәш алып бара торган уннан артык сайтыбыз бар, аларга хәбәрчеләр алдык. Фәнни эшчәнлек тә бер урында тормый. Берничә "түгәрәк өстәл" утырышлары үткәрдек", - дип билгеләп үтте Н.Гарипов. Үзәкнең җитәкчесе хәбәр иткәнчә, "Касыймия" мәдрәсәсендә якшәмбе саен укулар узачак. "Шәкертләр килә башлады, ике-өч төркем формалашты", - диде ул. Аның сүзләреннән аңлашылганча, киләсе елда Тукай урамындагы 38 нче йортта Галимҗан Баруди музеен ачу да күздә тотыла.

"Вәлиулла хәзрәтнең интернет-телевидение оештыру хыялы да бар иде, шуңа күрә без гамәлдәге iman.tv сайтын вәгазьләрдән тыш, көндәлек яңалыклар белән баетырга уйлыйбыз. Аналитика да кертеп җибәрергә кирәк", - дигән фикерен җиткерде Н.Гарипов.

Татарстанның баш казые Җ.Фазлыев Вәлиулла Якупов турында хатирәләрен яңартып, аның тарафыннан гамәлгә ашырылган эшләрне күңеленнән үткәрде, бергәлектә китап чыгарып йөргән чакларын искә төшерде, эшкә тотынганда аның алдан күрүчәнлек сыйфатын ассызыклап узды: "Ул үткен теле, тирән фикере белән күпләрне дәртләндереп йөрде. Аның ил күләмендә вәгазьчеләрне җыеп, форум оештыру идеясе белән янып йөргәнен дә хәтерлим. Безгә аның шушы тормышка ашмаган хыялларын чынга ашырырга омтылырга кирәк. Шул вакытта аның рухы шат булыр".

**Гөлнар ГАРИФУЛЛИНА**

# Мөселман кардәшләребез — Көнбатышта

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

булып тормыйлар. Шулай итеп, массакүләм миграцияне хәрәкәтләндерүче төп көчләр булып икътисади, сәяси, ягъни күп тапкырлар сөйләнгән шәхес иреге һәм кеше хокуклары сәбәп булып тора. Мөселманнарның Көнбатыш яшәү рәвеше биргән бу бәрәкәтләрне аңлый алулары куанычлы:

"Без Франциядә хатын-кызлар ирегенең ни рәвешле аңлануын Әфганстанда хатын-кызлар ирегенең ничек булуыннан аера белергә тиешбез. Монда - урамда булган вакытта хатын-кыз һәрвакыт полициягә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә ала, ягъни Франциянең җәмәгать пространствосында аңа куркынычсызлык тәэмин ителгән"

(Рәшид Некказ. Бизнесмен. Франция. http://www.islam-today.ru).

Некказ әфәндедән өзек китерүне исә Әфганстанда хатын-кызларга куркынычсызлык тәэмин ителми кебегрәк нәтиҗәләр белән дә дәвам иттерергә мөмкин булыр иде. Ләкин бу мәсьәлә ошбу мәкаләбезнең кысаларыннан чыгып китә, шуңа күрә карала торган темага кире кайтыйк. Хәзерге вакытта безгә, әгәр дә мөселманнар җитәрлек дәрәҗәдә аек акыл күрсәтеп, чынбарлыкны адекват кабул итсәләр һәм чит монастырьга үз уставың белән йөрмиләр, дигән гади һәм борынгы хакыйкатьне аңларлык һәм аның буенча тормыш алып барырлык дәрәҗәдә генә булса да элементар психик сәламәтлеккә ия булсалар, мөселманнарның Көнбатыш җәмгыятьләренә интеграциясе проблемасы чишелгән булыр иде икәнлеген аңларга вакыт. Иран һәм Согуд Гарәбстанында европача киенгән хатын-кызның берүзенә генә аның белән бергә баручы җирле кешедән башка урамнан үтү мөмкинме соң? Юк, бу мөмкин эш түгел, чөнки бу илләрдә җирле традицияләрне хөрмәт итүне һәм хатын-кызларның тиешенчә киенүен, тиешле кыяфәттә булуын таләп итүче махсус кануннар кабул ителгән. Ләкин, ислам традицияләре тарафдарлары булмаган хатын-кызлар өчен андый таләпләр кую каян алынган соң? Бәлки, андый таләпләр, мөселман булмаган хатын-кызлар мөселманнар арасында мөсеманча киенергә тиеш, дигән таләпләр Коръәннең үзендә үк язылгандыр? Юк, Коръәндә андый күрсәтмәләр бирелмәгән. Димәк, башка дин вәкилләрен ислам дресс-кодын үтәргә мәҗбүр итү - Изге Язмаларның "дин эшләрендә мәҗбүр итү кулланылырга тиеш түгел" дигән күрсәтмәсенә каршы килә. Шуңа да карамастан, мондый хәл мөселман илләрендә норма кебек кабул ителә. Ә ул вакытта, Көнбатыш илләре хөкүмәтләренең үз дәүләтләре мәнфәгатьләрен яклап, кешеләрнең тышкы кыяфәте буенча кайбер нормалар куеп кануннар кабул итүе ни өчен мөселманнар тарафыннан дискриминация буларак кабул ителә? Ачык күренеп тора, бу мәсьәлә гади дини диспут кысаларына гына сыеп бетми, чөнки ул, элементар мораль кагыйдәләрне үтәүгә генә кайтып кала. Ә бу мораль кагыйдәләр бик гади: чынлап та тәрбияле дини кеше, башкалар арасыннан артык аерылып торырга тырышмаячак һәм үзенең кайсы дин вәкиле икәнлеген башкаларга кирәгеннән артык фаш итеп, күрсәтеп йөрмәячәк.

Ләкин бу проблеманың әйтелмәгән бер ягы бар. Ул шуннан гыйбарәт: Көнбатыш илләре хакимиятләре, тыю буенча шундый чаралар кабул итеп, үзләре үк ... ислам тарафдарлары булып чыгыш ясыйлар! Мондый раслау, әлбәттә, бәхәсле дә кебек, тик беренче карашка гына. Алда әйтеп кителгән тыюлар, мәсәлән, Бельгияне алыйк, бары тик хатын-кыз киемнәренең йөзне каплап йөртә торган өлешләренә генә кагыла. Әгәр дә без Коръәнгә мөрәҗәгать итсәк, анда хатын-кызларга йөзләрен ниндидер тукыма артына яшерергә кирәклеге турында таләпләр бар, дип интерпретация бирерлек берни дә таба алмабыз. Шулай итеп, безнең бу эшебез бөтенләй башка юнәлеш ала: үзләрен мөселманнар дип күрсәтүче Көнбатыш хатын-кызлары Коръәндә күрсәтелмәгәнчә эш итәләр, ә Көнбатыш илләренең кануннары бу хатын-кызларны Коръән таләпләре буенча киенергә мәҗбүр итә. Димәк, проблема кайбер мөселман хатын-кызларының кайсы диндә икәнлекләрен демонстрацияләп, башкалардан аерылып торырга тырышуларында. Ә чынбарлыкта исә, моның чын динилеккә бер катнашы да юк, ул чамасыз күпергән эго-нәфеснең ямьсез бер чагылышы гына. Әлбәттә, кайбер мөселман галимнәре язган шәригатькә сылтамалар ясарга була, анда без хатын-кызларның ничек киенеп йөрү турындагы кайбер кагыйдәләрен дә таба алабыз, тик кайсы мөһимрәк соң: Аллаһ иңдергән Коръәнме, әллә гади бер галимнәр язган шәригатьме? Әгәр дә шәригать Коръән Сүзләренең үзенә үк каршы килә икән, бу исә шәригатьнең үз проблемалары, ә йөзләрен каплап, тоташ кара киемнәр киеп йөрүче кешеләр арасында яшәргә туры килүе аркасында үзләрен бик уңайсыз хәлдә тойган Көнбатыш илләре халкының түгел.

*(Ахыры бар.)*

**Күзәтүне Айдар ХӘЙРЕТДИНОВ әзерләде**

# Әхлаклы булу — заман таләбе

**Шөкер, безнең халкыбыз да сөенечле вакытларга, күңелле көннәргә килеп җитте. Ислам диненең ватаныбызда аякка басу, тернәкләнү, күтәрелү чоры бу. Үзебез теләгән дини китапларны уку, мәгънәсен халыкка аңлату, мәктәпләрдә ислам диненең асылын төшендереп, Аллаһ кушканнарны үтәп, ул тыйганнардан тыелып яшәргә инандыру мөмкинлегебез бар.**

Балтач районы мәктәпләрендә ислам кануннарына нигезләнеп әхлак кагыйдәләрен укыта башлауга быел унбиш ел тулды (бездә 1997-1998 нче уку елыннан башлап алты мәктәптә әхлак дәресләре укытыла башлады). Бүгенге көндә районның барлык татар мәктәпләрендә һәм хәтта Югары Субаш, Чепья, Балтач кебек төрле милләт вәкилләре укыган мәктәпләрдә дә бу дәресләр укытыла. Дәресләргә укучылар үз теләкләре һәм әти-әниләр ризалыгы белән йөриләр. Хәзерге вакытта мондый дәресләр социаль-педагогик түгәрәк статусында алып барыла.

Балтач районында төрле милләт вәкилләре үзара аралашып, дус-тату яшиләр, милләтара һәм дини каршылыкларга бәйле низагларның булганы юк. Менә өченче уку елы инде Урта Көшкәт урта мәктәбендә православие дине һәм әдәби әсәрләр нигезендә әхлак кануннары өйрәтелә. Аны рус теле һәм әдәбияты укытучысы Светлана Николаевна алып бара. Һәм ул һәр елны дүрт-биш мәктәптә үткәрелә торган ачык дәресләрдә һәм чараларда актив катнаша, чыгышлар ясый, фикерләрен уртаклаша. Быел үзе дә ачык дәрес күрсәтергә җыена. Ул әхлак мөгаллимнәре өчен бердәм программа төзүдә дә катнашты.

Әйткәнемчә, һәр уку елында без дүрт-биш мәктәптә ачык дәрес һәм дәрестән тыш чара карап, тәҗрибә уртаклашабыз, фикер алышабыз, яңа методик алымнарны дәресләрдә актив кулланырга өйрәнәбез.



Дөрес, җәй көне дә тик ятмыйбыз. Тирә-як районнардан да йөзләрчә баланы җыйган мөселман балалар Сабан туе үзе генә дә ни тора! Ул һәр елны Бөрбаш авылында үткәрелә, узган елны анда мөфти Илдус хәзрәт Фәиз дә катнашкан иде. Мәчетләр каршында оештырылган җәйге җыеннар да елдан-ел күбрәк баланы үзенә җәлеп итә, балалар ул лагерьларны көтеп алалар, теләп йөриләр. Бергәләп төрле дини бәйрәмнәр үткәрү дә халкыбызның асылына кайтуы өчен бер этәргеч булып тора. Еш кына балалар әти-әниләрен җитәкләп мәчетләргә алып килә. Хәер, болары аерым тема.

Бу язмам Алан гомуми урта белем бирү мәктәбендә "Заманча белем һәм тәрбия бирүдә әхлак укытуның актуаль мәсьәләләре" дип исемләнгән семинардан алган тәэсирләрем турында.

Алан - иң беренчеләрдән булып әхлак дәресләре укытыла башлаган мәктәп. Аның хәзерге директоры, филология фәннәре кандидаты Рәҗәп Фәтхетдин улы Бәдретдинов мәктәпнең элекке традицияләрен үстерү, ныгыту һәм алдынгы технологияләр белән баетуга күп көч куйган.

Күптән түгел генә узган семинарга ул үзенең остазы, фәнни җитәкчесе, филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловны да чакырган иде. Остаз белән шәкерт бергәләп "Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" әсәрендә әхлакый мотивлар" дигән тема буенча IX сыйныфта ачык дәрес бирделәр. Дәрестә укучылар "Йосыф хикмәтләре" китабы авторы, Балтач имам-хатыйбы Рамил хәзрәт Бикбаевка да сорауларын бирә алдылар. Алар үзләрен кызыксындырган "Пәйгамбәрләр гөнаһлымы?" һәм "Стенага рәсем ясау Йосыф кыйссасы язылган заманда тыелганмы?" дигән сорауларына китап авторының кызыклы һәм дәлилле җавапларыннан канәгать калдылар.

Әлбәттә, директор абыйлары, профессор һәм китап авторы үткәргән кызыклы һәм мәгънәви дәрес укучылар хәтерендә мәңгегә уелып калыр.

Мин үзем тагын шуңа сокланып утырдым. Укучылар актив, мөстәкыйль фикер йөртәләр һәм фикерләрен ышандырырлык итеп дәлилли алалар. Бигрәк тә малайларның активлыгы гаҗәпләндерде. Шулай булмыйча, әхлак мөгаллимнәре арасында бердәнбер ир-егет Айрат абыйлары Гыйбадуллин укыта бит аларны! Ул VIII сыйныфта "Гамәл һәм гыйбадәт" дигән темага дәрес күрсәтте.

Киң карашлы, мөстәкыйль фикерле балалар тәрбияләү бурычын үтәрдәй тел-әдәбият дәресләрен Рәҗәп Бәдретдинов укыта икән. Бер семинарда ике ир-егетнең дәресен караган юк иде әле!

Башлангыч сыйныфлар мөгаллимәсе Т.М. Хәбибуллина быелгы уку елыннан мәктәпләргә кертелгән "Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәнияте нигезләре" (элегрәк ул "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" дип атала иде. - ред.) фәненнән "Мөселманнар тормышының биш кагыйдәсе" дигән тема буенча үзенчәлекле һәм үрнәк булырдай дәрес күрсәтте.

Мөнәҗәтләр, моңлы, мәгънәви җыр-шигырьләр тыңлап ял итеп тә алдык. Алан мәктәбе укучыларының иҗади таланты белән таныштык.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# МӘҮЛА КОЛЫЙ ХИКМӘТЛӘРЕНЕҢ КЫЙММӘТЕ

**Белгәнебезчә, Казан ханлыгы яулап алынгач килеп чыккан иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә халкыбыз чукындыру, ээзәрлекләү сәясәтенә дучар була. Моңа каршы тору өчен татарлар рухи корал итеп ислам динен ала, шул рәвешле генә милләт булып сакланып кала. Чөнки ислам дине төрле авырлыклардан чыгу юлларын күрсәткән, кешене рухи яктан тынычландыручы, көч бирүче фактор булып торган.**

Моны татар язучылары һәм шагыйрьләре бик яхшы аңлап алганнар һәм халыкка да аңлатуны үзләренә бурыч итеп куйганнар. Шул исәптән, Мәүла Колый исемле татар шагыйре дә шундыйлар рәтендә була. Ул шушы бурычын җиренә җиткереп үтәү һәм татар халкының милләт буларак саклfavorite калуына зур өлеш кертү өчен "Хикмәтләр" дип аталган шигырьләр җыелмасын иҗат итеп, халыкка тәкъдим итә. Исеменнән үк күренгәнчә, аның һәр шигырендә ниндидер бер хикмәт яшеренгән, фәкать шуны ача белү зарур.

Мәүла Колый әсәрләренең язылу урыны: "Әйтелде Шәһре Болгар кәндләрендә", - дип күрсәтелә. Бу сүзләрдән аның хикмәтләре Шәһре Болгар тирәсендәге авылларның берсендә язылуы аңлашыла. Шагыйрьнең чын исеме - Бәйрәмгали Колыев. Татар галиме Марсель Әхмәтҗанов язганча, ул 1678 елда үз иптәшләре белән Биләр шәһәренә күчеп нигез кора. Алар мөселман мәдәнияте үзәкләрен саклап калу нияте белән күченәләр. Нәтиҗәдә, Биләрдә мөселманнар яши торган торак пункт барлыкка килә. Монда татарларның ныгый баруы патша хөкүмәтенә ошамый. Моның ише урта гасыр мөселман мәдәни мәркәзенең татарларны оештыру үзәге булып китүендә христиан дәүләте үзенә куркыныч күргән. Шунлыктан, бу төбәктән татарларны куып таратып, анда рус хәрби үзәге оештыру планына керешәләр.

Билгеле, XVII гасырда Идел буенда суфичылык идеяләре аеруча көчәеп киткән. Дин эшеннән һәм хөкүмәт идарәсеннән читләштерелгән руханилар, галим-укымышлылар арасында суфичылык идеологиясе шактый кулай җирлек таба, аларның күңел халәтенә аваздаш булып чыга. "Кеше авыр тормыштан ярдәм сорап Аллаһка мөрәҗәгать иткән. Иске Болгар хәрабәләрендәге "изге" каберлекләргә, гыйбадәтханәләргә суфи-дәрвишләр, догачы габидлар килеп тулуы моңа бер мисал", - дип яза әдәбиятчы галим К.Дәүләтшин.

Шулай итеп, Мәүла Колый үзенең халкына шундый тынгысыз заманда кирәкле киңәшләрен, үгет-нәсыйхәтләрен бирүне үзенең бурычы итеп саный. Чөнки тормышта җәбер-золымның соңгы чиккә җитүен күреп торган нинди әдипнең йөрәге әрнемәсен дә, ничек бу турыда уйланмасын?

Мәүла Колый иман саклау мәсьәләсенә бик киң туктала. Үзенең хикмәтләренең күп җирләрендә ул иман белән дөньядан үтү өстенлекләрен санап үтә:

"Иман берлә үлсәм диү өмидем вар,
Иман әйтү - үлгән колга рәхмәт дуслар".
Шулай ук:
"Бу дөньядин иман берлә үтәр булса,
Гүрдә юлдаш гүр эчрә ятар, имеш.
Оҗмахка илтер, кыямәт көн йитәр булса
Оҗмах өмид идеп, иман әйгем килер".

Мәүла Колый бик тынгысыз бер чорда яши. Бу елларда илдә җәбер-золым түзә алмаслык дәрәҗәгә җитә. Гаделсезлектән котылу, динен һәм милләтен саклап калу өчен татар халкы актив көрәшкә күтәрелә. Халык арасында азатлык идеяләре тарала башлый, әмма бу кузгалышлар рәхимсез рәвештә бастырылып килә. К.С. Дәүләтшин язганча, крестьян кузгалышларын бастыру царизмга колониаль сәясәтне тагын да шәфкатьсезрәк үткәрү өчен нигез бирә. Шушы сәбәпләр нәтиҗәсендә йортсыз-җирсез калган хәерче-гарипләрнең саны хисапсыз арта. Өстәвенә, бу елларда таралган төрле эпидемияләр, ачлык һәм хәерчелек халык өстенә күтәрә алмаслык афәт булып төшә. Мондый бәхетсез адәмнәр, әлбәттә, дөньядан туя, бу авырлыклардан котылу юлын күрә алмаганлыктан яшәүнең мәгънәсен югалта. Менә шушы өметсезлеккә баткан, язмышына рәнҗегән бәндәләрнең күңелен юатуны Мәүла Колый үзенең бурычы итеп саный".

Мәүла Колый гарипләр турында язганда тәннәре зәгыйфь яки имгәнгән кешеләрне генә күздә тотмый, бәлки, җаннары, күңелләре имгәнгән, рәнҗетелгән, кыерсытылган кешеләрне күздә тота. Бу исә чукындыру сәясәте белән дә бәйле булган. Автор татар халкының тормышлары искиткеч авыр булуы, хәтта аларның тыныч кына ятып үләрлек урыннары да юклыгын җан тетрәткеч юллар белән тасвирлый:

"Гарипләргә тормага йорт-мәкян каны?
Баш агырса, әҗәл йитәр, куркар җаны, -
Олуг-кардәш кыла алмас сәне гани,
Гариплектә үлем килсә, дөшвар иркән.
Башында ултырмага ятасы юк,
Өстендә хәсрәт йияр анасы юк.
Уңлы-суллы, хәлен сорар иясе юк, -
Бер үлмәке меӊ үлмәкдин яман иркән,
Гарипләргә үлем килсә, моңлыг башы,
Юк аның гүргә куяр карендәше.
Аш кылмагай, гарип өчен тикмә кеше, -
Гариплектә килгән үлем шул тик иркән".

"Мәүла Колыйның гарипләр турындагы хикмәтенә таянып, шуны әйтергә була: шагыйрь бу әсәрендә кыерсытылган ярлы халык вәкилләренең канлы яшь түгүен чагылдыра алган. Чөнки шагыйрь үзе дә, тормыштан аерылган ниндидер дәрвиш-аскет булмыйча, ватандашларының аһ-зарын күреп, тоеп яшәрлек актив шәхес булган. Авыр хәлләргә дучар ителгән "бичара"ларга теләктәшлек күрсәтеп, аларга ярдәм кулы сузарга теләгән һәм башкаларны да шуңа чакырган", - дип яза филология фәннәре кандидаты К.С. Дәүләтшин.

"Мәүла Колыйның йөзгә якын хикмәтләренең ким дигәндә яртысында авторны бик уйландыра торган глобаль тема - үлем темасы ята. Моның сәбәбе беренче чиратта, әлбәттә, автор яшәгән авыр тормыш шартларында, идеологик торгынлык һәм халыктагы рухи пессимизмда. Мәүла Колыйның үлем турында уйланулары, нигездә, ислам дине өйрәтмәләреннән читкә чыкмый", - дип билгеләп үтә филология фәннәре докторы Ә.Т. Сибгатуллина.

Мәүла Колый татар халкына бу коточкыч авыр хәлдән чыгу юлын күрсәтергә омтыла. Бу юл - Аллаһы Тәгаләгә таянып һәм сабыр итеп, дошманнар алдында ныклык күрсәтү. Мәүла Колый нык тору дигәндә дошманнарны корал белән түгел, ә иман ныклыгы һәм сабырлык белән җиңүне күздә тота. Чөнки татар халкы инде бик күп мәртәбә корал белән каршы чыгу аркасында бик күп кеше кырылды, һәлак булды. Бу сынауны кеше беркайчан да берүзе генә үтеп чыга алмавын белгәнгә, таянырга ниндидер бер терәк кирәк булганга, шагыйрь бу терәк итеп Аллаһы Тәгаләне күрсәтә. Сынаулар никадәр авыррак, күбрәк булса, кешенең Аллаһы Тәгаләгә таянуы да шулкадәр арта. Мәүла Колый халык үзе үч ала алмаганлыктан, бу үчне Аллаһка калдырырга үгетли, чөнки Аллаһ залимнәрне Кыямәт көнендә, һичшиксез, җәзага тартачак икәнлеген әйтә. Мондый төр сынауларны хәтта пәйгамбәрләр, әүлияләр да күрә. Мисал итеп әдип Ибраһим пәйгамбәрне китерә. Аны Нәмруд исемле патша утка ата. Әмма Аллаһы Тәгаләгә чын күңелдән таянганга күрә, Аллаһ аны коткара. Шулай ук хикмәтләрендә Җирҗис кыйссасы да китерелә. Ул дине өчен дүрт тапкыр җанын биреп, ахыр чиктә җиңүгә ирешә:

"Бу дөнья газапларын Җирҗис күрде,
Ул, газапта, дүрт кат Хакка җанын бирде.
Ул хәлдә икән, Хак күзенә күренү торды, -
Шул вакытта Хак дидарын күрмештер ул".

Шулай ук Йосыф, Әюб пәйгамбәрләрне телгә алып, аларны үрнәк итеп күрсәтә. Бу пәйгамбәрләр, әүлиялар Аллаһка таянып һәм сабыр итеп, ахыр чиктә уңышка, җиңүгә ирешәләр. Мәүла Колый аларны үрнәк итеп биреп, халыкка бу авырлыклардан чыгу юлын күрсәтә. Ул хәтта үлем белән янасалар да, гомереңә куркыныч янаса да, барыбер иманны саклауда нык торырга, кирәк икән җаныңны корбан итәргә кирәк икәнлекне белдертә:

"Ихлас илә һәркем кылса Хакның эшен,
Тәгать кылып Хакга еглап түкәр яшен;
Хакка бирер корбан өчен җанын-башын,
Хакны эстәгән баш җандин кичмәй булмас".

Мәүла Колый динне саклауда бик нык сабыр итәргә куша. Сабыр иткәндә генә Аллаһ уңыш һәм җиңү бирәчәк икән. Чөнки пәйгамбәрләр дә сабырлык аркасында гына җиңүгә ирешкәннәр:

"Сабыр берлә Әюп тапты сиххәт үзен
Сабыр берлә Ягкуп ачты күрмәс күзен.
Сабыр берлә Йосыф тапты дәүләт йөзен,
Сабыр сүзен телдин җөда итсә булмас".

Мәүла Колый Аллаһка һәрвакыт сыена һәм Аннан һәрвакыт саклавын һәм рәхмәтен сорый, аның бөеклеген, кодрәтен кат-кат искәртеп тора һәм Аллаһ мөэминнәрне үз яклавы астына ала, дип мөрәҗәгать итә. Мөэмин кеше һәрвакыт Аллаһның саклавын тойсын өчен Хозыр Ильясны искә ала:

"Туннары илә, мәңге суына чумды анлар,
Ул сәбәбтин тузмас анлар кигән туннар.
Кемдин хушнуд булып, кыйлса дога монлар,
Дөнья-ахирәт дәүләтен бирер булгай.
Яланда азсаң, йә суда булса хәтәр,
Анларга иткел нияз, мәдәд итәр,
Азмыш улырсың, юл түндерер ярдәм итәр,
Һәм дәрьяда йеп салып тартар булгай".

Шулай итеп, Мәүла Колый иманны саклауда нык торырга, сабыр итәргә, Аллаһы Тәгаләгә таянырга, Аннан яклау көтәргә чакыра. Берүк Аллаһтан башка бүтән затка табынудан катгый рәвештә тыя:

"Билең игеп, куя күрмә башың потка,
Баш бирде Изем сәҗдә кыйлгаймы дип".

Мәүла Колый кешенең үз иманын саклап калу өчен үлүендә дә бернинди куркыныч нәрсә күрми, чөнки, аның фикеренчә, иманлы кеше генә ахирәттә чын тормыш белән яши башлый, ә бу дөньяда хайваннар кебек динсез яшәүнең әһәмиятен күрми.

Беркемгә дә сер түгел, иман кешенең тормышында мөһим роль уйный һәм зур урын алып тора. Кешенең бу дөньядагы һәм ахирәттәге бәхете нәкъ менә аның иманына, дөреслегенә, чисталыгына бәйле. Мәүла Колый да укымышлы кеше булганга, бу турыда яхшы белгән, аңлаган һәм үз халкы өчен кайгырган. Ул заманда дин тотуы бик авыр булган: М.Колый яшәгән заман көчләп чукындыру, дин өчен эзәрлекләнү вакытына туры килә. Кешеләрне төрле ысуллар белән христиан диненә кертү юллары уйлап табыла: көч белән, төрле льготалар, матди ярдәм итү юлы белән һ. б.

Шулай итеп, Мәүла Колыйның хикмәтләр китабы татар халкына динен саклап калырга ярдәм итү, киңәшләр бирү, килгән бәлаләрдән котылу юлларын күрсәтүдән гыйбарәт. Мәүла Колый әсәрен шигырь белән биреп, үзенең киңәшләрен, үгет-нәсыйхәтләрен үтемлерәк кабул ителүенә ирешә. Ул татарларның үзе яшәгән чорда килеп чыккан проблемаларын күрә белгән һәм милләттәшләре өчен психолог функциясен дә үтәгән.

**Айдар ГАЙНЕТДИНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты**

# Йөз еллык тарихы булган мәчеттә – Корбан ашы

**Узган гасырда Мамадыш районының бары тик ике авылында гына йөз елдан артык манараларын горур тотып айлы мәчетләр басып торды. Берсе - Түбән Ушмада, икенчесе - минем туган авылым Уразбахтыда.**

Түбән оч мәчетенең манарасын кисеп мәктәп иткәннәр, өске мәчет (ул без яши торган өйнең каршында) манарасын шәмдәй тотып, 47 ел клуб, 28 ел склад ролен үтәде. Ремонт, хәстәр күрмәгән мәчетнең манарасы 100 елдан соң бер давылда ауды. Алланың рәхмәте белән, зур манарасы бер кешегә дә зыян салмыйча тип-тигез булып төшеп җиргә ятты. Икенче елны ук аның урынына иманлы кешеләр яңа мәчет салып куйдылар. Башлап йөрүчесе - егерме ел имам-хатыйб булып торган Зиннур хәзрәт Шакиров. Хәзерге вакытта мәчеткә йөрүче картлар аның эчен-тышын тәртипләп торалар. (Хәзер мәчет газ белән җылытыла.) Гошер, фитыр сәдакалары белән беррәттән, авылыбыздан чыгып киткәннәр дә матди ярдәм күрсәтеп, савап алып торалар. Дин тоту тыелган чорда да иманлы картларыбыз, карчыкларыбыз күп булды. Үлгәнче алар үз кыйблаларына тугры калдылар.



Ялгыз Шәфига әбине дә искә алып китми ярамас. Бу әбидә һәр җомга саен намазлар укылып, илгә-җиргә тынычлык, иминлек, бәрәкәт, татулык, муллык, тигезлек сорадылар. Шәфига әбинең, һәр атна саен пәнҗешәмбе көнне барып, идәннәрен юа идем. Буяу күрмәгән идән. Аны кер сабыны, мунчала белән агартып юдыра иде ул. Көче булганда үзе генә юа торган булган. Кешегә ышанып тапшырмаган бу эшне...

Менә шушы йөз еллык тарихы булган мәчеттә җомга саен мәчетебез мулласы Шаяздан Гасыймов вәгазьләр укый. Рамазан аенда авыз ачтыру, Корбан гаетендә ашлар үткәрү күркәм бер гадәткә әверелде. Шушы араларда гына мәчеттә Корбан ашы үткәрелде. Изге чара районыбыз мөхтәсибе Илһам хәзрәтнең тирән эчтәлекле вәгазе белән башланды. Вәгазьләр, котлау сүзләре тыңланганнан соң, барысы да намазга тезелде. Җәмәгать белән саф-саф тезелеп, намаз укуның тәмен белсәгез иде сез. Мин үзем бик зур шатлык кичерәм. Күркәм мәҗлес аш-су өстәлендә дәвам итте. Илһам хәзрәт, җыелган халыкка хәләл ризыклар гына ашарга өндәп, янә бер вәгазь сөйләде. Ул арада икенче кунагыбыз - үзләрендә җомга намазын уздырып, Әхмәд Ясәви мәчете имам-хатыйбы Нурислам Газизов килеп җитте. Ул да халыкка эчтәлекле, файдалы вәгазь-нәсыйхәтләр сөйләп үтте. Уразбахты авылында Корбан ашын уздыруга хәйрия ярдәме күрсәтүчеләрнең - авылыбыз абыстае Нурания Усмановага, кадерле әнием, тәмле ашлар пешерүче Сания Ганиуллинага, сыйнигъмәтләргә искиткеч бай табын оештыруга өлеш кертүчеләрнең барысына да Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын. Кайтыр юлга чыккач: "Илһам хәзрәт, без сезнең белән килгәндә Уразбахты юлына асфальт салсыннар иде дип дога кылган идек", - дидем. Иншалла, быелгы Корбан ашына тип-тигез асфальт юлдан бардык. Догабызның, үткәргән ашларыбызның кабуллыгына чын күңелдән сөендек.

**Фирая МИНГАЛИЕВА,**
**Мамадыш.**

# СӨЕКЛЕ РӘСҮЛЕБЕЗ (СГВ) ТӘКЪДИМ ИТКӘН ДӘВА

**Салкыннар якынлашкан саен, чирләү куркынычы да арта. Үзеңне һәм гаиләңне авырып китүдән ничек сакларга? Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) сәламәтлекне ныгыту өчен үзенең дин-кардәшләренә нинди табигый дәвалану чараларын тәкъдим иткән соң?**

Берничә гасыр үтеп, химия һәм фармацевтика өлкәсендә байтак кына ачышлар ясап, миллионлаган пациенталарда химик препаратларның йогынтысын өйрәнгәннән соң да кешелек җәмгыяте, нәтиҗәлерәк һәм куркынычсыз булып саналган табигый дәвалану чараларына өстенлек бирә. Бу уңайдан Рәсүлебез (сгв) тәкъдим иткән шифалы табигый медицина препаратлары аерым урын алып тора. Галимнәр Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләреннән бал, кара тмин, алоэ, кыст һинди, зәгъфран һ. б. бик көчле терапевтик һәм дәвалау үзлекләренә ия булуын ачыклаганнар. Мөхәммәд пәйгамбәр (сгв) нәкъ менә шушы чараларны төрле чирләрне дәвалаганда кулланырга тәкъдим иткәнлеге мәгълүм. Әнә, бүгенге көндә аларны кайберәүләр ризыкка кушыла торган биологик актив матдәләр, икенчеләр - парафармацевтик, өченчеләр - нутрицевтиклар дип өйртә. Әмма аларның асылы моңа карап үзгәрешсез кала бирә. Бу табигый матдәләр кулланганда кеше организмына тискәре тәэсир итми, ә бәлки аны сәламәтләндерү, чистарту һәм ныгытуда ярдәм итә, адәм баласының гомерен озайта һәм аны бәрәкәтлерәк итә.

Салкын тиюдән саклану һәм аны дәвалауда Рәсүлебез (сгв) тәкъдим иткән чаралар турында сүз алып барганда, иң әүвәл адәм баласының сәламәтлеге сагында торучы табигый "сакчы" - иммунитет турында телгә алу урынлы.

Шунысы бәхәссез: нык иммунитет саф-чиста организмда гына була ала. Хәдисләрнең берсендә суның да чистарту үзлеге искә алына. Моны заман медицинасы да инкарь итми. Беренчедән, организмдагы су кытлыгы инсульттан алып нерв авыруларына кадәр булган төрле чирләргә китерергә мөмкин. Икенчедән, гомер буе дөрес тукланмау нәтиҗәсендә безнең организм бик нык пычрана. Биредә мөселманнарның көндәлек ризыгында итнең, төрле майлы ашамлыкларның, камыр ашларының гаять күп булуын искәртеп китү урынлыдыр. Организмның шулай итеп пычрануы иммунитетның кимүенә китерә. Шуңа күрә, бүгеннән үк тәүлегенә бер литр ярым кайнамаган саф су эчә башлыйк. Ул организмны чистартачак. Суны ашарга 15-30 минут кала эчү файдалы. Балаларны да ризык кабул итү әдәбенә өйрәтегез. Ризык ашаганда су эчәргә, чүпрә салып пешерелгән икмәк ашарга, организмны шлаклар белән баета торган баллы һәм газлы эчемлекләргә, төрле казылыкларга һәм ысланган балык ашарга күнектермәгез.

Рәсүлебез (сгв) бер хәдисендә сенна үләненең (александрийский лист) уңай сыйфатлары турында искәртеп узган. Эчәкләрегезне шушы үлән ярдәмендә чистартудан тыелмагыз. Күзәнәкләрнең иммунитетын арттыру өчен аларны токсиннардан чистарту зарур. Шуннан соң чистарган организмны табигый чаралар белән тазарту эше тагын да нәтиҗәлерәк һәм тизрәк барачак.

Кара тминның файдасы турында байтак фәнни хезмәтләр язылган. Аның турында Рәсүлебез (сгв) каткат искәртә. Соңгы елларда галимнәр кара тминның вилочковый бизләргә тәэсир итүе һәм аны эшләтүе турында гаҗәеп ачыш ясады. Әлеге бизләрнең кеше организмының саклану үзлекләре өчен җаваплы булуын онытмыйк. Сынаулар вакытында кара тмин кеше организмындагы Т-лимфоцитлары, Т-киллерлар һәм башка күзәнәкләрнең ишәюе, аның чирләрдән дәвалану һәм саклану көчләрен арттыру өчен җавап бирүен күрсәтте.

Иммунитетны арттыруның яңа ысулын тәкъдим итәбез. Иртән ач карынга 30 мл мангостан җимешеннән ясалган Ксанго согын һәм бер бал кашыгы кара тмин маен, ә кич белән ашка кадәр шул ук микъдарда май белән 30 мл алоэ согын эчәргә. Төшке аш вакытында 30 мл күләмдә әлеге соклар майсыз гына эчелә. Болай эшләгәндә организм зарарлы матдәләрдән һәм токсиннардан арына, иммунитет ныгый, невратения, аллергия һәм тире авыруларыннан котыла.



Алоэ согын эчеп дәвалану да искиткеч зур әһәмияткә ия. Шунысы бар, медицинада алоэның "Вера" дигән сорты гына файда китерүен истә тотарга кирәк. Калганнары исә хәтта яман шеш авыруы китереп чыгарырга сәләтле икән. Ә иң куркынычсызы - АКШта җитештерелгән "Алоэ Форевер" согы. Ул ашкайнату процессларына булышлык итә, организмнан токсиннарны һәм шлакларны чыгара, бактерияләргә, вирусларга һәм гөмбәчекләргә каршы тора, су һәм майларны эретүче витаминнарны үзләштерүне арттыра, тире авырулары, шул исәптән псориаз белән интегүчеләрнең күзәнәкләрен янә "сафка бастыру"га ярдәм итә, иммун системасының эшен җайга сала, ашкайнатуны яхшырта, моннан тыш әлеге сок табигый антибиотик булараk авыртуны киметә һәм күзәнәкләрнең яңаруын тәэмин итә.

Бер бал кашыгы кара тмин маена бер бал кашыгы лецитин кушып эчсәң, дерматит һәм аллергиядән дә дәваланырга мөмкин. Әлеге катнашма бавырдагы ташларны җимерә, нерв системасын торгыза, хәтерне яхшырта һәм, әлбәттә, иммунитетны ныгыта. Аны өч ай дәвамында көненә ике тапкыр ашаганчы кулланырга кирәк.

Чыршын (перга) һәм чәчәк серкәсе турында да аерым искәртеп үтик. Көн саен бер бал кашыгы бал белән шуларны тел астына салсагыз, салкын тиюне бар дип тә белмәссез. Кышкы салкын кичләрдә бер чеметем кара тмин белән кардамонның вак итеп төелгән орлыкларын кофега салып эчсәгез дә файдасы тимичә калмас.

**Гөлназ МИЯССӘРОВА әзерләде ("Islam today" мәгълүматианалитик федераль порталыннан алынды)**

# Балалар өчен Яңа ел бәйрәме узды

**25 ноябрь көнне Казан шәһәренең Әниләр мәчетендә һиҗри исәп буенча Яңа елга багышланган бәйрәм чарасы үтте. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан оештырылган чарада Яшел үзән районының балалар йортыннан, "Госмания" мөселман мәктәбеннән, шулай ук шәһәребезнең күп балалы гаиләләреннән килгән йөзләп сабый катнашты. Алар өчен махсус театраль тамаша, мавыктыргыч уеннар, шулай ук Коръән уку бәйгесе оештырылган иде. Бәйрәмне үткәрүдә РИУ студентлары да зур активлык күрсәтте.**

**Соңыннан сабыйлар РИУ ашханәсендә кунак булдылар, аларның һәрберсенә дә истәлекле бүләкләр тапшырылды.**







# Әхлаклы булу — заман таләбе

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

Шуннан соң күңелдә кайнаган фикер-тойгыларны уртаклашу өчен кара-каршы сөйләшүгә җыйналдык. Аның темасы "Әхлаклы булу заман таләбеме?" дип билгеләнгән иде.

Сөйләшүдә мәктәптә күп еллар эшләгән районның мәртәбәле мөгаллимнәре Нурия Вәлиева, Надирә Хаҗиева, Мәймүнә Нурмиева, Рәмзия Мөэминова, районның әхлак мөгаллимнәре, әти-әниләр, журналистлар, КФУ профессоры Хатыйп Миңнегулов, район прокуроры Зөфәр Абитов, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, район мәгариф бүлеге методисты Гадения Гарипова катнашты.

Бик күңелле, мәгънәле сөйләшү узды. Кодрәтемнән килсә, мин бу тапшыруны республикабызның "Татарстан - Яңа гасыр" каналыннан күрсәтер идем, ул аңа һичшиксез лаек.

Менә шулай эшлиләр безнең мөгаллимнәребез. Һәр дәресне республика дәрәҗәсендә яңалык алырлык, тәҗрибә тупларлык итеп үткәрәләр. Моның өчен алар иң әүвәл Җәлил хәзрәткә рәхмәтле. Чөнки ул төпле, акыллы киңәшләре белән һәрдаим ярдәм итеп тора.

**Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА, Балтач районы Шубан төп мәктәбенең югары категорияле әхлак мөгаллимәсе**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 1.12.12 | 7:19 | 8:49 | 13:02 | 15:11 | 16:15 | 17:45 |
| *Якшәмбе* | 2.12.12 | 7:21 | 8:51 | 13:02 | 15:10 | 16:14 | 17:44 |
| *Дүшәмбе* | 3.12.12 | 7:23 | 8:53 | 13:02 | 15:10 | 16:14 | 17:44 |
| *Сишәмбе* | 4.12.12 | 7:24 | 8:54 | 13:02 | 15:09 | 16:13 | 17:43 |
| *Чәршәмбе* | 5.12.12 | 7:26 | 8:56 | 13:02 | 15:09 | 16:12 | 17:42 |
| *Пәнҗешәмбе* | 6.12.12 | 7:27 | 8:57 | 13:02 | 15:09 | 16:12 | 17:42 |
| *Җомга* | 7.12.12 | 7:28 | 8:58 | 13:02 | 15:08 | 16:11 | 17:41 |
| *Шимбә* | 8.12.12 | 7:30 | 9:00 | 13:02 | 15:08 | 16:11 | 17:41 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 22 (165) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9427.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 29 ноябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**